| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>ШӘҺӘР СОВЕТЫ |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| 22 февраль, 2017 ел | № 15/8 |

Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге 21/8 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерә Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе, 2006 елның 13 мартындагы «Реклама турында» 38-ФЗ санлы Федераль законның 19 маддәсе, шәһәр Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге 21/8 санлы Карары (Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы 26/10, 2014 елның 17 апрелендәге 30/9, 2014 елның 10 июлендәге 31/17, 2014 елның 9 декабрендәге 35/10 санлы Карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 32-36 пунктчаларны өстәргә:

«32) сәнәгать-производство территорияләре – производство-эшлекле (тәҗрибә производстволары белән фәнни-тикшеренү институтлары, техник хезмәт күрсәтү цехлары белән сәүдә предприятиеләре, нәшрият-типография бүлеге белән мәгълүмат үзәкләре һ.б.), сәнәгать (азык-төлек һәм җиңел сәнәгать, приборлар төзү, машина төзү, төзелеш материаллары җитештерү һ.б.), коммуналь-склад (җылылык электр станцияләре территорияләре, аэрация станцияләре, котельныйлар, электроподстанцияләр, газ бүлү узеллары, чүп эшкәртү заводлары, шәһәр инженерлык инфраструктурасының башка корылмалары, склад корылмалары, территорияне механик җыештыру машиналарын куеп тору урыннары, зиратлар, крематорийләр), транспорт һәм инженерлык объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән территорияләр һәм производство төзелеше участоклары һәм производство зоналары рәвешендә формалашалар;

33) казып ташлау – җир эшләренең тышкы төзекләндерү элементларын бозу белән бәйле теләсә кайсы төре, үз эченә ала: җир асты инженерлык коммуникацияләренә яки челтәрләренә планлы яисә аварияле ремонт; җир асты һәм җир өсте төзекләндерү объектларын төзү яки ремонтлау; яңа инженерлык коммуникацияләрен, челтәрләрен яки корылмаларын төзү; археологик эзләнүләр үткәрү;

34) җир эшләре – ул туфракны уеп алуны (эшкәртүне), аны күчерүне һәм билгеләнгән урынга салып куюны үз эченә алган төзелеш эшләре комплексы;

35) бункер-туплагыч – ул күләме 1,5 $м^3$ артыграк булган зур габаритлы чүп-чарны җыю һәм саклау өчен контейнер;

36) яшел утыртмаларга зыян китерү – агач-куак үсемлекләренең ябалдашлары, агач-куак үсемлекләренең ботаклары бөтенлеге, кәүсәсе, тамыр системасы, газонның һәм туфракның тере өске катлавы бозылуга һәм декоратив сыйфатлары югалуга китергән механик, термик, химик һәм (яки) башка йогынты, шулай ук яшелләндерелгән территорияләрдә туфракның яшел утыртмаларның үсеше тукталуга китерми торган, үсемлекләр өчен зарарлы булган маддәләр белән пычрануы.»;

2) 332 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«332. Физик һәм юридик затлар, аларның оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә, милек хокукында яки башка әйбер хокукында ия булган җир кишәрлекләрендә, биналарда, корылмаларда һәм ян территорияләрдә (әгәр әлеге затлар калдыкларның хуҗасы икәне расланса, яки күрсәтелгән калдыклар аларга әйләнешкә кертелсә) җыештыру эшләрен оештыруны, шулай ук гамәлдәге җир законнары, Торак урын территорияләрен карап тотуның санитар кагыйдәләре (СанПиН 42-128-4690-88), җир кишәрлеген арендалалау килешеү, әлеге Кагыйдәләр нигезендә санитар чистартуны тәэмин итәргә тиеш.»;

3) 378 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«378. Территорияне язлы-көзле җыештыруны 16 октябрьдән 14 апрельгә кадәр үткәрү зарур һәм чүп-чарны, коелган яфракларны, кар һәм бозны чыгаруны, урамнарга хлоридлар катнашында ком сибүне алдан планлаштыру кирәк.»;

4) 391 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«391. Түбәләрдән ташланган яки оешмалар территориясеннән, төзелеш мәйданнарыннан җыелган карны 24 сәгать эчендә чыгарырга кирәк. Карны оешмалар территориясеннән читкә этеп чыгару тыела. Махсус оешмалар тарафыннан чистартылган урыннарда түбәләрдәге карны юл өслекләреннән җыелган карны чыгарганчы төшерергә һәм бергә җыярга кирәк.»;

5) 422 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«422. Контейнер мәйданчыкларын һәм калдыкларны саклауның башка урыннарын, зур габаритлы калдыклар өчен махсус мәйданчыкларны, торак төзелеше территорияләрендә чокырларны урнаштыру урыннары Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Яр Чаллы шәһәрендәге, Актаныш районындагы Территориаль бүлеге белән килештереп, торак йорт яны

территориясен җыештыручы оешма тәкъдиме буенча Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.»;

6) 441 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«441. Торак төзелеш территорясендәге контейнерлар һәм бункер-туплагычлар техник торышы буенча төзек, буялган, хуҗасының, каты көнкүреш калдыкларын чыгаручы подряд оешмасының реквизитлары, калдыкларны чыгару вакыты күрсәтелгән маркировкага ия булырга тиеш. Каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар һәм бункер-туплагычлар тыгыз ябылучы капкачлар белән җиһазландырылырга тиеш.»;

7) 447 пунтта:

- 3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) контейнерларга, бункер-туплагычларга һәм контейнер мәйданчыкларына ирекле үтүне тәэмин итәргә тиеш;»

- 4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерларның, чүп савытларының, бункер-туплагычларның төзек торышта булуын тәэмин итәргә, тулып, шәһәр территориясе пычрануга китерергә тиеш түгел;»

- 5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5), чүп савытларын, контейнерларны, бункер-туплагычларны һәм контейнер мәйданчыкларын, сыек калдыклар өчен чокырларны вакытында чистартуны һәм дезинфекцияләүне тәэмин итәргә;»

- 8 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) контейнерларны, бункер-туплагычларны һәм контейнер мәйданчыкларын вакытында буяуны һәм юууны тәэмин итәргә;»;

8) 457 пунктта «тыгыз» сүзен «тоташ» сүзенә алыштырырга»;

9) 459 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләрен сузганда, үзгәрткәндә, ремонтлаганда казу белән бәйле эшләрнең барлык төрләре һәм башка җир эшләре төзелеш урманнарын, коймаларын яки башка киртәләрне урнаштырып башкарылырга тиеш. Территорияне рөхсәтсез казу тыела;»;

10) 472 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 6 пунктчаны өстәргә:

«6) сәнәгать-производство территорияләре.»;

11) 484 пунктның 10 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

12) 485 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

13) 489 пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) кискән урыннарында агачларны һәм куакларны, юкка чыгарылган яки зыян китерелгән урыннарында газонны һәм чәчәк түтәлләрен вакытында торгызу;»;

14) 489 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 13 пунктчаны өстәргә:

«13) яшел утыртмаларны саклау һәм торгызу буенча комиссия тарафыннан бирелгән рөхсәт кәгазе булганда, яшел утыртмаларны кисү, ябалдашларын кисү һәм утырту, аварияле һәм башка гаддәт тыш хәлләрне ликвидацияләү буенча эшләр башкарылган очраклардан тыш.»;

15) 496 пунктта:

- 8, 10 һәм 26 пунктчалар үз көчен югалткан дип танырга;

- түбәндәге эчтәлектәге 27 һәм 28 пунктчаларны өстәргә:

«27) ташланган транспорт чарасы дип танылырга мөмкин булган, автомобильләр, җәяүлеләр йөрүгә, территорияне җыештыруга каршылыклар тудыручы төзек булмаган транспорт чарасын сакларга;

28) үлән капламы биеклеген 10 см дан арттырмаска.»;

16) 503 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«503. Төзелеш яки җир асты коммуникацияләрен сузу белән бәйле рәвештә, агачларны һәм куакларны кисәргә мәҗбүр булганда, Башкарма комитет карары белән расланган Киселгән яшел утыртмалар бәясен хисаплау һәм компенсация өчен яшелләндерү үткәрү методикасы (алга таба – Хисаплау методикасы) нигезендә саналган яшел утыртмаларны торгызу бәясе түләтелә.»;

17) 542 пунктның 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) Парковкалар, машина кую урыннары территорияләрен санитар нормаларны һәм янгын чыгу куркынычсызлыгы кагыйдәләрен саклап карап тоту. Ян территорияләрне санитар чистартуны даими уздырырга, тыгыз ябылучы капкачлар белән чүп контейнерлары (савытлары) урнаштырырга, каты көнкүреш калдыкларын, карны даими чыгаруны тәэмин итәргә. Парковкалар, машина кую урыннары территорияләрендәге контейнер мәйданчыклары асфальт яки бетон белән капланырга, өч яктан койма белән әйләндереп алынырга тиеш.»;

18) 571 пунктта 1 һәм 2 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) төзелеш территориясенең бөтен периметры, казу һәм җир эшләре башкару урыннары буенча койма урнаштырырга. Койма гамәлдәге дәүләт стандартларына, нормаларына һәм кагыйдәләренә туры килергә тиеш;

2) төзелеш мәйданчыгы, казу һәм җир эшләре башкару урыннары коймасының гомуми тотрыклылыгын, ныклыгын, ышанычлылыгын, эксплутацияләү куркынычсызлыгын тәэмин итәргә;»;

19) 571 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) төзелеш мәйданчыгы, казу һәм җир эшләре башкару урыннары коймасының, шулай ук мәгълүмәти-басма продукциянең тиешле техник торышын, аның чисталыгын күзәтеп торырга, вакытында пычрактан, кардан, боздан чистартырга;»;

20) 585 пунктның 2 пунктчасы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Койма тоташ булырга тиеш, чит затларның төзелеш мәйданчыгына, казу һәм җир эшләре башкару урыннарына керүен булдырмый калырга тиеш;».

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме — Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ